# КАРАР

**28 ноябрь, 2020 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Татар Толлысы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 27-28 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 5 һәм аннан күп күпбалалы гаиләләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Татар Толлысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Татар Толлысы авылында чишмәләрне төзекләндерү (будка урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Татар Толлысы авылында һәйкәл янына җәяүлеләр юлы ясау (проект-смета документларын эшләү, материал сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен түләү);
- Татар Толлысы авылында балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу, балалар мәйданчыгына җәяүлеләр юлы ясау (проект-смета документларын эшләү, материал сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен түләү).
- ТатарТоллысы авылында юлларны кыш көне кардан чистарту?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 304 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 186 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 186 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Татар Толлысы авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныrга.

2.Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Көндезгә уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 5 һәм аннан күп күпбалалы гаиләләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Татар Толлысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Татар Толлысы авылында чишмәләрне төзекләндерү (будка урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Татар Толлысы авылында һәйкәл янына җәяүлеләр юлы ясау (проект-смета документларын эшләү, материал сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен түләү);
- Татар Толлысы авылында балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу, балалар мәйданчыгына җәяүлеләр юлы ясау (проект-смета документларын эшләү, материал сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен түләү).
- ТатарТоллысы авылында юлларны кыш көне кардан чистарту?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип таныrга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Чарлы
авыл җирлеге башлыгы Э.Н.Козлов